СОВЕТ КОРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная Площадь, д.1, с. Коргуза,
422586

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАРАГУЖА АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Үзәк ур., 1 нче йорт, Карагуҗа авылы,
422586

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48,

**РЕШЕНИЕ** — **КАРАР**

07.04.2026 — с. Коргуза — 6-37

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379)

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Советның кайбер карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

"Коррупциягә каршы көрәш турында" 25.12.2008 елгы 273-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнар, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы нигезендә Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Көчен югалткан дип таныргa:

1.1. "Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең керемнәре, чыгымнары турында белешмәләр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында" Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советының 07.03.2023 ел № 31-169 карары;

1.2. "Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук, әгәр бу белешмәләрне бозып күрсәтү җитди булмаса, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен җаваплылык чаралары күрү тәртибен раслау турында" Карагуҗа авыл җирлеге Советының 16.06.2020 ел № 66-299 карары;

1.3. "Депутатка, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук, әгәр бу мәгълүматларны бозу гамәлдә булмаса, үз иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен җаваплылык чараларын куллану турында Карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында" Карагуҗа авыл җирлеге Советының 07.03.2023 ел № 31-167 карары;

1.4. «Карагуҗа авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан тәкъдим ителгән. “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә “Югары Ослан муниципаль районының Карагуҗа авыл җирлеге” муниципаль

берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибен раслау турында» Югары Ослан муниципаль районы Карагуҗа авыл җирлеге Советының 27.09.2017 ел № 30-135 карары .

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм Карагуҗа авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга мөмкин.

Совет рәисе,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районының
Карагуҗа авыл җирлеге башлыгы Д.В.Плохов